# Ул Рамазан аенда бер Кадер Кичә

Запись Масгуды Шамсутдиновой



Ул Рамазан аенда бер Кадер Кичә, Хак Тәгалә Күк Капусын анда ача,
Колларына ул төннәрдә Рәхмәт сачә, мөэминнәргә моннан тәкый Рәхмәте вар.
Һәрбер кеше бу айларда Руза тотар, һәр кичәдә Тәрәвихны дәхи үтәр,
Гөнаһларын барчасын Хак гафу итәр, Рамазанның шундый олуг көннәре вар.
Ул Аллаһыдан Пәйгамбәргә йөз мең сәлам, вәгъдә кылды өммәтеңә шәфәгать кылам,
Салават әйтер торыр мәләк дәвам, Кыямәт Көн шәфкать кылыр көннәре вар.

©